**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге Иске Тәкмәк торак пунктында гражданнар җыены карары**

**12.11.2020** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең Иске Тәкмәк торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлардан кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең Иске Тәкмәк авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:

- Урам яктырткычларын ремонтлау;
-буш участокларны әйләндереп алу;
- Комсомольская һәм Железнодорожная урамнар тыкрыгына ут кую;
- балалар мәйданчыгын төзекләндерү, мәйданчык өчен элементлар алу;
- зират төзекләндерү, зират коймаларын ремонтлау;
- Речная, Комсомольская урамнарын ремонтлау, вак таш җәю; юлның вак таш җәелгән нигезен төзәтү.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Аксар авыл җирлеге башлыгы__________________ Ю.И.Гильманов